

Үткән атнада Кочкурово районы Подлесная Тавла авылында милли мордва мәдәниятенә багышланган берничә чара vткәрелә.
Владимир Ромашкин исемен-дәге «Этно-кудо» музей-йорты террито-риясендә «Кой» (традиция) агач буенча III тобәкара рәсем фестивале старт алды. Резчиклар, агачны чукып сын ясаучылар фестивале Мордовиядән генә тvгел, Чуаштан, Удмуртия, Башкортстан, Ульяновск, Пенза һәм Мәскәv олкәләреннән дә осталарны жыйды. Кон уртасында кунакларны музей-йортнын капка тобендә ипи-тоз белән каршы алдылар. Жирле «Толава» халык фольклор-этнография ансамбле фестиваль кунакларын монлы жыр белән сәламләде. Кунаклар читән коймага куелган истәлекле тасмалар бәйләделәр, Владимир Ромашкин бюстына чәчәкләр салдылар. Традиция буенча, Нишкепазга озкс (моление) vткәрелгән һәм изге эштә ярдәм сораган ата-бабаларны хәтерләгәннәр. Фестивальнен рәсми олеше Петр Рябов фестивальдә катнашучыларга, Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Минсалим Тимергазеевнын морәжәгатен укыган.
Аннары кунакларны һәм анда катнашучыларны Кочкурово районы башлыгы Светлана Герасимова сәламләгән:
- Агач буенча «Кой» фестивале безнен республикада гына тvгел, ә илебезнен башка субъектларында да популяр. Бvген Подлесная Тавла авылы мордва халкынын милли мәдәният vзәкләренен берсе булып тора. Ул «Торама чакыруы» туристик маршрутына кертелгән. Республика кунаклары биредә зур теләк белән ике мәдәният объектында – Подлесная Тавла эксперименталь балалар сәнгать мәктәбендә һәм Владимир Ромашкин исемендәге «Этно-кудо» музей-йортында булалар. Шуна кvрә резчиклар фестивале биредә vзенчәлекле әрзә мәдәниятен саклау һәм популярлаштыру урынында vткәрелә. Хәзерге доньяда милли гореф-гадәтләргә ярдәм итv бик кирәк. Сезнен әсәрләрегез, хормәтле оста-резчиклар, әлеге игелекле максатка хезмәт итәчәкләр. Сонытнан сәхнәгә резчик-осталар чакырылды, алар исеменнән сәламләv сvзен удмурт командасы вәкиле Виктор Яковлев житкерде: «Безнен фестиваль Владимир Ромашкинга багышланган. Анын максаты - vз тормышын vзенчәлекле әрзә мәдәниятен популярлаштыруга багышлаган кеше турында искәртv. Традицион һонәрләрне, гореф-гадәтләрне саклап калган кешеләр булганда халык та яшәячәк. Мондый фестивальләр даими vткәрелергә тиеш…».
Чаранын тантаналы олеше тәмамланугa ук пычкылар тишелде, балта һәм стамескалар

шакылдады. Осталар vз идеяләрен агачта тормышка ашырырга кереште. Аларнын ни буласын сонрак – якындагы ял коннәрендә кvрергә момкин булачак, чонки эш бер генә конлек тvгел.
Александр Артемьев, Ульяновск олкәсе Кузоватово авылы: «Бу фестивальдә мин беренче ел гына катнашмыйм: 2012 елда биредә булдым инде. Ул чакта мин агачтан мифологик персонажнын - урманнарнын Алласы скульптурасын кистем. Быел кыр һәм уныш яклаучысы - «паксява» эшләячәкмен». Ә Минибулат Абдрахимов, Башкортстан Республикасы: «Музей каршында беренче тапкыр оештырылган фестивальдә катнашам, әмма Подлесная Тавласында инде ике тапкыр булдым. Быел мин Иненармунь (Боек кош) кисәргә тырышачакмын. Мордва мифологиясе буенча ул тере, шулай ук су, урман һәм ундырышлылык ата-бабасы... мина бу тема бик ошый».
Роман Рябов, Подлесная Тавла авылы кешесе: «Мин таган-балансир (качели) эшләячәкмен, чонки «Этно-кудо» музей-йорты территориясендә алар юк. Әмма бу Такталы гади балка тvгел, анда мордва мифологиясе элементлары кулланылачакмын. Анда балаларны саклаячак ой композициясен һәм атны – таулы уенчыгынын традицион элементы булачак композицияне кисv планлаштырыла».

**Наилә Насырова**